УДК 398.4

*Л.Х. Дәүләтшина*

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МИФОЛОГИК СИСТЕМАСЫНА БЕР КАРАШ

В статье рассматриваются мифологические представления татар как часть общетюркской мифологии, проводится последовательный анализ источников и научной литературы для описания персонажей высшей и низшей мифологии, привлекается богатый полевой материал для характеристики современного состояния мифологической системы татар. Народная демонология рассматривается автором как многосоставная система, включающая не только ряд персонажей, но и весь круг основных мотивов и сюжетов, связанных со сферой «низшей» мифологии.

**Ключевые слова:** традиционная культура, мифология, персонаж, высшая мифология, народная демонология, поверье.

Төрки-татар мифологиясенең тарихын һуннардан башлау кабул ителгән. Һуннарның тарихын, мәдәниятен, мифологик карашларын чагылдырган чыганаклар нигездә кытай, грек, әрмән авторларына карый. Кытай хроникалары XIX гасырда Н.Я. Бичурин (Иакинф) тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителә [Бичурин, 1950, т. 1], текстологик тикшеренүләр үткәргән Н.В. Кюнер [Кюнер, с. 7–8] билгеләвенчә, әлеге мирас бүгенге көндә дә иң төгәл хезмәтләрнең берсе булып кала. Кытай чыганакларында төрки кабиләләрнең килеп чыгышына бәйле генеалогик легендалар, дәүләт төзелеше, йола-гадәтләренә бәйле мәгълүматлар теркәлсә, әрмән чыганаклары (Лазарь Парбский, Малала, Феофан Исповедник, Мовсес Каланкатуаци, VII гасыр әрмән географиясе һ.б.) V–VII гасырларда Төньяк Кавказ һәм Каспий буйларын иңләгән «гун иленең» тарихын һәм мәдәниятен ачыклый. «Гун иле»нең мифологик күзаллауларын чагылдырган хезмәтләр арасында иң бай мәгълүмат туплаганы – әрмән тарихчысы Мовсес Каланкатуациның «История страны албан» хезмәте. 682 елда христиан миссиясе белән Каспий буе территориясенә килгән тарихчы язып алган мәгълүматлар борынгы төрки аллалар пантеонын, төркиләрнең дини-мифологик карашлар системасын реконструкцияләргә мөмкинлек бирә [Гмыря, с. 5].

Тарих фәнендә һуннар ике исем астында йөри: Азия һуннары (хунн/хунну) һәм Европа һуннары (гунн) [Гумилев, 1998, кн. 1, с. 266]. Хуннар дип б.э.ның II гасырына кадәр Үзәк Монголия һәм Байкал арты далаларында яшәгән этноска әйтәләр. Ә гуннар дип Бөек халыклар күчеше вакытында Каспий буе Дагстан территориясенә килеп чыгып, шунда бер-ике гасыр яшәп, угыр, сармат кабиләләре белән аралашып, шуның нигезендә физик кыяфәтләрен үзгәртеп, асыл-

да яңа этноска әверелгән, әмма төрки телләрен саклап калган кабиләләрне күздә тоталар [Дәүләтшин, б. 17]. Һуннар һәм Борынгы Төрки каганлыгындагы дин, мифологик карашлар хакында шактый язылган инде [Гумилев, 1993; Кляшторный, 1964; Кляшторный, 1977; Потапов, 1991; Стеблева, 1972]. Һуннар затка әйләндерелгән галәмгә, күккә табынганнар. Бу чордагы чыганакларда әле Тәңре исеме очрамый, әмма Төрки каганлыгында киң таралыш алачак тәңречелек диненең оешып килүе инде билгеле була. Һуннарда чыгып килүче кояшны каршы алуның махсус ритуалы да булган. Алар иртән чыгып килгән кояшны баш иеп сәламләгәннәр [Гумилев, 1967, с. 59].

Кытай чыганакларында («Хань-шу»да) күрсәтелгәнчә, һуннар гадәт буенча елына өч мәртәбә Лун-цы храмында (лун – аждаһа) беренче, бишенче һәм тугызынчы айларда, Сюй дигән көндә, күк, җир һәм үзләренең рухлары хөрмәтенә корбан чалу йоласы үткәргәннәр. Һуннарның иң зур бәйрәме кытай календаре буенча бишенче айга, якынча май ахырына һәм июнь башына туры килгән [Бакиров, б. 20; Алексеев, с. 214]. Һуннарга кагылышлы кытай чыганакларына караганда, «шаньюй (һуннар башлыгы) һәрчак шаманнардан аяклары бәйләнгән атлар белән ырым ясата торган булган» [Бакиров, с. 21; Материалы..., вып. II, с. 15].

VI гасырда Каспий буе Дагстан территориясенә килеп чыккан көнбатыш гуннары да Тәңрихан (Тенгри-хан), яшен алласы Гуар/Куар һәм җир рухы хөрмәтенә корбан чалу йоласы үткәрә торган булганнар. Тәңре-ханга корбан чалу йоласы аның үзен гәүдәләндерә торган биек агачлар үскән изге урманнарда (роща) үткәрелгән. Биредә аңа багышлап атлар чалганнар, аларның каны белән җирне туендырганнар, башларын һәм тиреләрен агач ботакларына элгәннәр, ә гәүдәләрен учакта яндырганнар [Каланкатуаци, с. 193–194, 200–201]. Шул ук вакытта Төньяк Кавказ гуннарының пантеонында Куар алласы булуы да билгеле. Тәңре-ханнан кала икенче рангтагы әлеге алла кояш/яшен алласы буларак күзалланган, һәм яшен суккан кешене яки хайванны гуннар Куар алласының корбаны дип исәпләгәннәр [Каланкатуаци, с. 200–201].

Һуннарның мифологик карашларында чагылыш тапкан пантеон VI–VII гасырларда Алтай, Көнбатыш Себер һәм Төньяк Монголия җирләрендә яшәгән Төрки каганлыклар дәверендәге Орхон-Енисей язмаларында ачыкланган дини-мифологик система белән тәңгәл килә. С.Г. Кляшторный фикеренчә, гунн – борынгы төрки – праболгар пантеоннарының тәңгәллеген һәм праболгар кабиләләренең (теле кабиләләре союзы) Үзәк Азия территориясеннән V гасырдан да калмыйча китүләрен исәпкә алганда, фәндә «борынгы төрки пантеон» дип исемләнгән катлаулы дини-мифологик системаның б.э. I меңьеллыгының уртасына кадәр формалашып бетүе шик тудырмый [Кляшторный, 1978, с. 62].

Борынгы төркиләр күзаллавында, Себер-Урта Азия мифо-

логияләрендәге кебек үк, дөньяның вертикаль моделе Югары, Урта һәм Җир асты өлешләреннән гыйбарәт. Урта дөнья белән Изге Җир-Су («Ыдук Йер-Суб») хакимлек итсә, Җир асты дөньясы «кешеләрне бер-берсеннән аеручы» һәм аларга «үлем хәбәрчеләрен җибәрүче» Эрлик-ханга буйсынган [Кляшторый, 1979, ч. 2, с. 91–95]. Югары дөньяның хуҗасы һәм борынгы төрки пантеонның югары алласы – илаһи Күк буларак кабул ителгән Тәңре кешеләр язмышы белән идарә итә, «күк төркләрнең яшәү рәвешен билгели», каганнарга акыл һәм хакимлек сыйфатларын бүләк итә һ.б. Төрки дәүләтләрдән мирас булып калган ташъязма истәлекләрдә, бигрәк тә Күлтәгингә багышланган Кече һәм Зур язмаларда, Тоньюкукка атап язылган язмада Тәңренең вазифалары ачыкланып бетә. Күк, Тәңре белән бәйле борынгы төркиләрдән калган карашлар Идел болгарларында да дәвам итә. Аның исеме Кол Галинең монгол яуларына кадәр язылган «Кыйссаи Йосыф» поэмасында һәм болгарларның XIV гасырга караган кабер таш язмаларында очрый [Урманчеев, б. 42–43]. Тәңре культы төрки һәм төрки-монгол халыклары яшәгән киң территориядә таралыш таба, хәтта XI гасыр галиме М. Кашгари әле ислам динен кабул итмәгән төркиләрнең «биек тауларны», «олуг агачларны» «Тәңре» дип атауларын яза [Дәүләтшин, б. 76].

IX–X гасырларда ислам дине рәсми рәвештә кабул ителеп, халык арасында да таралгач, Тәңре исеме, әкренләп, Алла исеме белән алыштырыла. Ислам белгечләре фикеренчә, «Тәңре төрки телләрдә Аллаһ сүзе белән бер үк мәгънәдә кулланыла» [Ислам, б. 151], вазифаларының уртаклыгы тәңречелек тәгълиматының ислам дине белән органик рәвештә керешеп китүенә китерә.

Югары дөнья алиһәсе Умай хатын-кыз башлангычын гәүдәләндерә һәм Тәңренең илаһи хатыны дип исәпләнә. Ул «кеше улларының» тууы белән идарә иткән, яңа туганнарның, сугышчыларның яклаучысы булган, аның белән бәйле ышанулар төрки халыкларның күбесендә бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән. Л.П. Потапов мәгълүматларына караганда, сагайлар, шорлар һәм билтерләрдә Умай – сабыйның, туган көненнән башлап, өч яшенә кадәрге җаны [Потапов, 1973, с. 271]. Татар халык мәдәниятендә Умайга бәйле ышануларның берничә кыйпылчыгы гына сакланып калган: Казан татарларында умай дип хатын-кызның аналыгын яисә бала урынын атыйлар [Брусько, с. 204]; Себер татарларында Умайны баланың кендеге белән тиңләштерәләр [Урманчеев, б. 44].

Урта дөньяның төп алласы Җир-су – җир, су культы белән бәйле булган һәм төркиләрнең яклаучысы, гөнаһ-гаепләре өчен җәза бирүче дип каралган. Византия тарихчысы Феофилакт Симокатта «борынгы төркиләр җиргә дан җырлыйлар» дип язган [Дәүләтшин, б. 59], кытай чыганакларында төркиләр тарафыннан илаһи дип кабул ителгән тау «җир алласы» дип аталган. Алтайлылар карашынча,

Җир-Су – 17 ярдәмчел рухалланың гәүдәленеше; алар карлы тау башында һәм елгаларның башланган җирендә гомер кичерәләр [Татар мифологиясе, б. 65]. Гомумән алганда, Җир-Су – табигать күренешләренең (тау, урман, елга, күл һ.б.) хуҗасы. Төрки халыклар мифологиясендә мондый рухлар ияләр дип атала, алар рух-хуҗа функциясен башкарып, төрле табигать объектларын саклап торалар. Идел буе, Урта Азия, Төньяк Кавказ, Көнбатыш Себер, Алтай һәм Саян таулары буенда яшәгән төрки телле халыклар мифологиясеннән дә бу күренешкә мисаллар табарга мөмкин [Мифологический словарь, с. 672].

Татар традицион мәдәниятендә югары мифологиягә кагылышлы күзаллаулар системасы көндәлек яшәештән төшеп калса да, бүгенге көндә татар халкының мифологик ышануларын реконструкцияләү өчен кызыклы чыганак ролен «түбән мифология», ягъни алла статусына ия булмаган ияләр, кара көчләр, рухлар, йола-гадәтләр, ышанулар, кешенең көндәлек яшәеше белән бәйле мифологик мәгълүмат үти. Ияләр табигать объектларының, кеше яши торган торак урыннарының хуҗасы буларак кабул ителәләр һәм, күңелләрен күрә белсәң, кешегә файдалы затлар буларак күзалланалар. Җен, албасты, убыр, өрәк, шүрәле һ.б. шундый түбән рухлар адәм баласының тормышында туган күңелсезлек, бәхетсезлек, акылдан язу кебек күренешләрнең сәбәпчесе буларак тасвир ителәләр. Түбән мифология персонажлары турындагы текстлар татар халкының төрле этник традицияләрендә күптөрле локаль вариантларда бүген дә саклана, бу төр текстлар экспедицияләр барышында күпләп язып алына.

Түбән мифология персонажларының бер өлешен тәшкил иткән ияләр табигать объектларына һәм кешенең торак-яшәү урынына бәйле, ягъни шуларның хуҗалары рәвешендә фараз ителәләр. Әлеге персонажлар белән бәйле текстлар рус фольклористикасында мифологик проза кысаларында өйрәнелә. Бу өлкәдә беренчеләрдән булып, Э.В. Померанцева түбән мифология персонажларына бәйле мөһим мәсьәләләрне күтәрә, рус фольклористикасында мифик зат белән очрашу мотивына корылган «быличка» һәм «бывальщина» (татар фольклористикасында – сөйләк, мифологик хикәят; башкортларда – хорафати хикәяләр һ.б.) дип аталган жанрларның хасиятләрен билгели һәм тематик классификациясен төзи. Галимә йорт тирәсендәге рухлар, табигать рухлары һәм черт дип исемләнгән өч тематик категориягә күрсәтә [Померанцева, с. 4]. Россия территориясендә яши торган халыклар фольклористикасында әлеге юнәлеш киң үсеш ала: мифологик хикәятләр кергән фольклор җыентыклары басыла (В.П. Зиновьев, Н.А. Криничная, К.Э. Шумов, О.А. Черепанова); билгеле бер этник традициянең мифологик күзаллауларын өйрәнүгә багышланган махсус хезмәтләр языла; мифологик сүзлекләр төзелә (М.Н. Власова, Ф.Г. Хисаметдинова, Ф.И. Ур-

манче); мифологик мотив күрсәткечләре эшләнә (С.М. Лойтер, Д. Климова); мифологик лексиканы анализлаган этнолингвистик хезмәтләр басыла (Н.И. Толстой, О.А. Черепанова, Е.М. Назарова, Е.Е. Левкиевская, Н.А. Архипенко, Ф.С. Баязитова һ.б.).

Йорт-каралты белән бәйле рух-хуҗалар арасында өй (йорт), абзар һәм мунча ияләрен атарга кирәк. Әлеге хезмәттә төп игътибар, йорт (өй) һәм абзар хуҗаларына юнәлтелә, чөнки алар функцияләре ягыннан бүгенге көндә иң актив персонажлар буларак тасвир ителәләр, ә менә мунча иясе турындагы карашлар бик аз һәм аны тулы бер мифик зат буларак күз алдына китерерлек түгел.

Йорт-каралты хуҗаларына (*йорт иясе, җорт хуҗасы, җорт бабай, өй анасы, Гамбәр ана, Дәсимә түти, кырсут, ызба иясе* һ.б.) ышану — татар халкының төрле этник төркемнәрендә киң таралган күренеш. Бу ияләшелгән, гадәти персонаж әллә ни куркыныч хәлләр белән бәйләнмәгән, шуңа күрә аның турындагы текстлар катлаулы, киңәйтелгән сюжетка корылмый. Бу төр персонажның төп гамәлләре – хуҗалыкта иминлекне саклау, үзе яраткан йорт хайваннарына ярдәм итү яки, киресенчә, яратмаган тереклек иясенә зыян салу, йортка бәла киләсе булса, алдан хәбәр бирү һ.б. Йорт иясе өйне бәла-казадан саклый, төннәрен чыгып, ихатаны карап йөри, йоклап калган хуҗаларны уята, кайгы-хәсрәт киләсе булса, алдан кисәтә [Давлетшина, 2015, с. 1023]. Әгәр дә төнлә йон эрләгәнне ишетсәң, бай булырсың, чабата үргәнне ишетсәң, хәерчелеккә төшәрсең, ди халык. Йорт иясе белән яхшы мөнәсәбәт урнаштыру өчен, аны ашатырга, аның белән сөйләшеп йөрергә, даими сәдака бирергә кирәк. Хуҗалар яңа йортка күченсәләр, йорт иясен дә үзләре белән алырга тиеш. Бу йола төрле төбәктә төрлечә башкарыла: йорт иясен я җәяүләп, я ат арбасына утыртып алып баралар, яңа нигезгә күченгәч, аңа атап аш үткәрәләр һ.б.

Татарларның традицион күзаллавы буенча хуҗалыкта өй иясе белән янәшә мөстәкыйль персонаж буларак күзалланган мал-туар хуҗаларына да (*хайван хуҗасы, Мәхүбә түти, абзар хуҗасы, ат иясе, аран иясе, киртә иясе* һ.б.) урын бар. Кайбер информантлар, һәр хайванның үз хуҗасы бар, диләр, әмма моңа мисаллар бик аз, күпчелек очракта аерма исемнәрдә генә күзәтелә. Әлеге персонажның тышкы кыяфәте хакындагы сыйфатламаның аз булуы «абзар иясе белән очрашсаң, аны качырасың һәм бәхетсезлеккә юлыгасың» дигән ышануга бәйле булса кирәк. Информантлар фикеренчә, һәркөн иртән абзарга кергәндә, хуҗа кеше, абзар иясенә качарга мөмкинлек бирер өчен, тамак кырырга тиеш. Шул ук вакытта аңа ниятләп дога уку һәм сәдака бирү дә гадәткә кергән. Гомумән алганда, мал-туар хуҗасы кешеләргә карата тискәре мөнәсәбәт белдерми, ул мәрхәмәтле, изге рух.

Мал-туар хуҗалары турындагы күзаллаулар комплексында татарлар арасында киң таралыш алган Зәнги бабай атамасы

игътибарны җәлеп итә. Себердә яшәгән татарлар хәтерендә сакланучы мөселман изгеләре культын тикшергән галимнәр Зәнги ата турындагы ышануларның Урта Азия һәм Идел буенда киң таралыш табуын дәлилләделәр. Әлеге персонажның асылында XIII йөздә яшәгән һәм С. Бакырганидан соң аның хатыны Гамбәр анага өйләнгән легендар зәнки дәрвиш [Яхин, б. 125] яки суфи шәехләрнең чынбарлыктагы тарихи прототибы Зәнги ата булырга тиеш. Риваятьләрдә ул Ташкент якларында көтү көткән, йөзгә-биткә тупас чалымлы, кара тәнле кеше буларак сурәтләнә. Аерым риваятьләр буенча, Зәнги ата һәм аның фикердәшләре Алтын Урдада ислам динен таратуда хәлиткеч роль уйнаган дип исәпләнелә [Культ святых, с. 85–86].

Халык телендә бу персонажны «Зәнки бабай» дип йөртәләр. Татар халкы малларның күпләп үрчүе, көр һәм сөтле булуы әлеге рухка бәйле дип әле дә ышана. Мал суйганда, «Зәнки бабай хөрмәтенә» дип әйтәләр, маллар көтүдә исән-сау йөрсен дип, Зәнки бабай рухына хәер бирәләр, аңа дип махсус ипи пешереп абзарга куялар һ.б. 1995 елда дини календарьда басылган юл догасында Зәнки бабай яклаучы буларак телгә алына: «И раббым! Бу сәфәремә мин сиңа ышанып, үземне сиңа тапшырып чыгам. Син миңа үзеңнең рәхмәтеңне сал, Хозыр галәйһиссәламне юлдаш кыл, Зәнки бабайны сакчы кыл» [Гыйльманов, б. 223]. Татарлар арасында Зәнки бабайга бәйле ышанулар ислам дине, суфичылык тәгълиматына бәйле рәвештә таралыш тапса да, тарихи персонажның функцияләре бу очракта үзгәреш кичереп, татар халкының мифологик күзаллаулар системасына органик рәвештә кереп китә һәм яңа ракурста ачыла.

Табигать культлары белән бәйле рух-ияләргә килгәндә, татарлар арасында төрле вариантларда аталып йөртелгән Хозер Ильяс (*Хызыр, Хозер, Хозер бабай, Хызыр Ильяс* һ.б.) хезмәттә функциональ яктан борынгы төрки традициядә җир һәм су стихиясе белән идарә итә торган персонаж, һәм ислам тәгълиматы аша килеп кергән Хозер / Ильяс пәйгамбәрләрнең кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән мифик зат буларак тәкъдим ителә. Хозер исеме Коръәндә аталмаган, әмма Рабгузи һәм Коръән тәфсирләрендә аңлатылганча, 18 нче сүрәнең 64 нче аятендә сүз Хозер хакында бара [Садекова, с. 133]. Халык ышануларында Хозер Ильяс юлчыларга юлдаш, адашкан кешеләргә ярдәм итә торган ак сакаллы карт буларак ачыклана. Татар халкында киң таралыш тапкан шундый риваять бар: бервакыт хәлле кешеләр яши торган авылга таякка таянган, ап-актан киенгән бер бабай килеп керә. Ул йортларга кереп, ризык сорый, әмма аны куып чыгаралар, этләрдән талаталар. Карт авылдан көч-хәл белән чыгып котылгач, бөтен йортлар да су төбенә китә. Авыл кешеләре куып чыгарган картның исеме Хозер Ильяс булган, дип сөйли халык. Бу сюжет Татарстанда гына түгел, башка регионнарда да очрый.

Экспедиция вакытында Хозер Ильяснык эш-хәрәкәтләре буенча табигать күренешләрен фаразлаганнарын да ишетергә туры килде. Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районында яшәүче татарлар арасында «Хозер канатын җилпегәч, чәчүгә чыгарга ярый» дип исбат ителә. Татарстанның Яшел Үзән районында 19 апрельдә кичтән карга таяк кадап калдыралар, иртән исә кар кимегән булса, яз иртә килә дип фаразлыйлар, әгәр кимемәгән булса, «Хозер әле таягын кырга ташламаган» диләр. Төмән өлкәсенең Ялутор районында салават күперенең бер башында Хозер, бер башында Ильяс утыра дип әйтәләр [Давлетшина, 2011, с. 780].

Хозер Ильяс төрки халыклар традициясендә дә киң таралыш таба. Төрекләр 23 апрельне язның беренче көне буларак билгелиләр һәм шуннан соң өч көн бәйрәм итәләр. Беренче көнне кырда учак ягыла, икенче көнне тозсыз икмәк пешерәләр дә, аны, көчле булсын дип, үгезгә ашаталар, өченче көнне исә капкага он сибәләр һәм анда Хызырның эзләре барлыкка килүен көтәләр [Cetin, s. 28–29]. Азәрбайҗаннарда да бу көн зур бәйрәм буларак исәпләнә. Алар 23 апрельдә чәчүгә чыгалар һәм көтү куалар. Үзбәкләрдә исә, инде игеннәрне җыеп алганнан соң, келәткә салынган ашлык өстенә җир кисәге салып, аны «Хызыр кесаки» дип атау гадәте бар [Садекова, с. 135]. Күрүебезчә, Хозер Ильяс, гаять катлаулы, борынгы төрки мифологик карашлар традициясе һәм ислам идеологиясе белән бәйле күзаллау системасының синтезы буларак, татар халкының традицион мәдәниятендә бүген дә әһәмиятен югалтмаган мифик персонажларның берсе.

Традицион халык мәдәниятендә таралыш тапкан түбән рухлар хакындагы ышанулар системасына килгәндә, ислам мифологиясенә кагылышлы җен, пәри, шайтан; үлгән кешеләргә мөнәсәбәтле барлыкка килгән утлы елан, өрәк, убыр, татар халык ышануларында киң таралыш тапкан бичура, шүрәле, албасты кебек персонажлар турында әйтергә кирәк. Әлеге персонажлар кешегә зарарлы яки битараф затлар итеп карала һәм чыгышлары белән иран мифологиясенә (дию, аждаһа һ.б.), ислам тәгълиматына (җен, пәри, шайтан һ.б.), төрки халыклар традициясенә (албасты, өрәк һ.б.), угор-фин халыкларының күзаллауларына (убыр, бичура, шүрәле) барып тоташа.

Татар халкының бүгенге көн мифологик күзаллауларында иң актив персонажларның берсе – җен. Ислам дине өйрәтүләре аша татар традицион мәдәниятендә үз урынын яулаган әлеге персонаж белән бәйле ышанулар Гарәбстан территориясендә VI–VII гасырларда яшәгән халыклар арасында ислам динен кабул иткәнче үк киң таралыш тапкан булган. Мөселман традициясе буенча, Аллаһы Тәгалә җеннәрне уттан яраткан һәм аларга аң биргән, дип исәпләнелә. Җеннәрнең күбесе Иблис белән бәйле булса да, кайберләре ислам динен кабул иткән булып санала [Мифы народов мира, с. 374], шуңа күрә халык ышануларында алар «шәйтани» һәм «мөселман» җеннәренә аерыла.

Татар халкының бүгенге көн мифологик күзаллауларында җен, бер яктан, кешегә зыян китерердәй персонажларны алыштырып килә, икенче яктан, аның үзенә генә хас функциональ кыры да оеша. Экспедиция барышында язып алынган текстларда информантлар әлеге персонажны *җен, чин, чин-сәхмәт, җен-зәхмәт, шайтан, зәхмәт* дип атыйлар. Җен көндәлек тормышта күзгә күренеп йөрми, ул гаиләсе белән параллель дөньяда яши, әмма, үзенә кирәк булганда, кеше, берәр әйбер, табигать күренеше һ.б. кыяфәтләргә керергә мөмкин. «Без аларны күрмибез икән, алар безне күрә. Сукыр тип әйтәтеләр җеннәр кешеләрне» (Төмән өлкәсе Ялутор районы Ревда ав.). Җеннең яшәү урыны буларак халык телендә иң еш искә алына торган урын – мунча, анда тамак кырып керү кабул ителгән, кояш баегач, көн уртасында һәм төн уртасында керү тыелган.

Җен белән бәйле фольклор текстлары иң күп өлешне тәшкил итсә дә, алар нигездә берничә сюжетка кайтып кала. Җен кешенең яши торган йортына үтеп кереп, йортка бәла-каза алып килергә мөмкин, шуңа күрә дә әлеге персонаждан саклану чаралары бүгенге көндә дә актив кулланыла (ишек өстенә ат дагасы, артыш таягы кую; ишекләрне, ризык өсләрен бисмилла әйтеп ябу, тәрәзә төпләренә ризык куюны тыю һ.б.). Әлеге мифик затның зәхмәте кешегә йорт эчендә генә түгел, ә бәлки юлда, җиде юл чатында, пычрак урында, ташландык нигезләрдә дә тиярга мөмкин. Бу очракта җен зәхмәтен кайтару белән бәйле гамәлләр башкарылырга тиеш.

Җеннең эшчәнлеге күп очракта бала алыштыру белән бәйле. Адәм баласын җен юкка гына урламый. Урланган бала үсеп җиткәч, җеннәр арасында имче функциясен башкара, чөнки кешегә җен зәхмәте кагылган шикелле, җеннәргә дә адәм зәхмәте йогарга мөмкин икән. Персонажның әлеге функциясе баланы саклау белән бәйле гамәлләр комплексын да барлыкка китерә (баланы һәм көмәнле хатын-кызны ялгыз калдырырга ярамый; ялгыз калдырырга туры килгән очракта тимер әйбер, сарымсак, артыш таягы, миләш ботагы куярга кирәк һ.б.).

Гомумән алганда, халык телендә җен дип аталып йөртелгән персонаж ислам дине өйрәтүләре нигезендә таралыш тапкан булса да, бүгенге көндә исемнәре, генезисы, тышкы кыяфәте ягыннан мөселман традициясенә якынлыгын саклаган хәлдә, функциональ яктан татар халкының мифологик күзаллауларына бәйле рәвештә шактый баеган һәм үзгә персонажга әверелгән.

Татар халкы һәм башка халыклар мифологиясе дә мифологик персонажлар турындагы күзаллауларны гына түгел, ә бәлки алар белән бәйле функцияләрне (куркыту, адаштыру, яклау, бастыру, зәхмәт җибәрү һ.б.), мифологик образларга бәйсез мотивларны (абага чәчәген эзләү, хәзинә эзләү һ.б.), мифологик лексиканы үз эченә алган катлаулы система буларак билгеләнә [Виноградова, Толстая, с. 16–44].

Өйрәнү объектын тәгаенләштерү материалның чикләрен дә киңәйтеп җибәрә. Мифологик персонажларга бәйле традицион рәвештә өйрәнелә торган жанрлардан (мифологик хикәят, легенда) тыш, эзләнүләр барышында ырым текстларын, йолагадәтләрен (йорт иясен яңа йортка күчерү, йорт иясенә ризык кую, җен алыштырган баланы кайтару, йорттан җен куу һ.б.), көндәлек тормыш белән бәйле гадәтләрне (су аркылы чыкканда җеп ташлау; мунчада әйбер калдырып чыгу, җен төкермәсен өчен ризык өсләренә ябу һ.б.), ышану, тыю, юрау кебек жанр формаларын исәпкә алу да бик мөһим.

Үз эчендә бай мифологик мәгълүмат туплаган ышанулар функциональ яктан сынамышларга якын тора, алар да нәрсәдер булачагын хәбәр итү, юрау өчен әйтеләләр. Әмма ышанулар практик тәҗрибәгә, табигать күренешләре белән бәйле күзәтүләргә түгел, ә бәлки мифологик фикерләү калыпларына корылган. Кеше хәтерендә мифологик мәгълүмат «менталь матрицалар» рәвешендә саклана [Неклюдов, с. 77–80], аларның һәрберсе коммуникация вакытында я тарайтылгын, я киңәйтелгән кыяфәттә чагылыш таба. Беренче очракта сүз ышану хакында барса, икенче очракта сүз мифологик хикәят турында бара. Бу күзлектән караганда, ышанулар мифологик мотивлар фонды буларак күзалланырга мөмкин.

Ышануларның эчтәлеге еш кына халыкның борынгы үткәненә, аның йола-ритуалларына барып тоташа. Көтү килгәндә, алдан кызыл сыер килсә, көн кояшлы булыр, әгәр дә кара сыер килсә, болытлы булыр дигән ышану бар. Бу фикерләү калыбы борынгы заманнарда яңгыр теләгәндә, корбанга кара сыер, аяз һава теләгәндә кызыл сыер чалу гадәте белән бәйләнгән. Ышанулар һәрвакыт халыкның мифологик-дини күзаллауларына нигезләнә, кешеләрнең магик тәҗрибәләре нигезендә барлыкка килгән фикри сөземтәләр рәвешен ала. Ышануларның байтагында мәҗүси һәм ислам мифологиясе белән бәйле карашлар бер-берсе белән үрелеп, еш кына бер-берсен баетып тора: «Җомга көн кер, идән юарга ярамый», «Аш-суның өстен ябарга кирәк – шайтаннар юына», «Артыш агачыннан җен курка» һ.б.

Халык ышанулары инде күптән кешенең көнкүрешеннән, яшәешеннән чыгып киткән төшенчәләрне, мифологик карашларны реконструкцияләргә дә мөмкинлек бирә. Себер татарларында соңгы елларда язып алынган информациягә караганда, яңа туган баланың бишеге тирәли «Алас, Алас» дип артыш агачын яндырып йөрү гадәте саклана. Информантлар аңлатуынча, әлеге гадәтнең нигезендә «Алас, Алас» дисәң, балага кара көчләр тими дигән ышану ята. Әгәр дә татар халкының мифологиясенә мөрәҗәгать итсәк, Аласның ут алласының исеме булуын күрербез. Себер татарларында туй вакытында, шушы сүзләрне әйтеп, атны ут аша сикертү йоласы булган [Валеев, с. 87]. Татар халкында «Эт тыны сөяк сындырыр» дигән кызыклы

ышану да бар. Н. Исәнбәт аңа түбәндәгечә аңлатма бирә: «элекке заманнарда тамакка кылчык я сөяк утырганда, авызга эт тыны җибәргәннәр» [Татар халык мәкальләре, б. 586]. Шулай итеп, ышанулар уйдырма яки хорафатларга корылган сүзләр генә булмыйча, татар халкының борынгыдан килгән дини-мифологик карашларының чагылышы, инде көндәлек тормыштан төшеп калган күренешләрнең саклану урыны буларак та күзаллананалар.

**Әдәбият**

*Cetin I.* Nevruz kutlamalarında ortak ve benzer pratikler / Uluslararası Nevruz Sempozyumu bildirileri: 21–23 Mart 2000, Ankara. Ankara: Kültür Bakanlığı, 2000. S. 28–29.

*Алексеев Н.А.* Общее в ранних формах религии якутов и тувинцев // Этнография народов Алтая и Зап. Сибири. Новосибирск: Наука, Сибирское отделение, 1978. С. 209–220.

*Бакиров М.Х.* Пратөрки бабаларыбыз иҗаты // Татар әдәбияты тарихы. I том. Казан, 2014.

*Бичурин Н.Я. [Иакинф].* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1950. Т. 1. 382 с.

*Брусько З.М.* В круге жизни. Казань: Ихлас, 2014. 224 с.

*Валеев Ф.Т.* Западно-сибирские татары во второй половине XIX – начале XX веков (Историко-этнографические очерки). Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. 232 с.

*Виноградова Л.Н., Толстая С.М.* К проблеме идентификации и сравнения персонажей славянской мифологии // Славянский и балканский фольклор. Верования. Текст. Ритуал. М.: Индрик, 1994. С. 16–44.

*Гмыря Л.Б.* Религиозные представления населения Прикаспийского Дагестана в IV–VII вв. (По данным письменных источников). Махачкала: Наука ДНЦ, 2009. 540 с.

*Гумилев Л.Н.* История народа хунну: в 2-х книгах. Кн. 1 / сост. и общ. ред. А.И. Куркчи. М.: Институт ДИ-ДИК, 1998. 448 с.

*Гумилев Л.Н.* Древние тюрки. М.: Наука, 1967. 504 с.

*Гумилев Л.Н.* Хунну. Степная трилогия. СПб.: Тайм-Аут – Компасс, 1993. 224 с.

*Гыйльманов Г.* Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, имтомнар, сынамышлар, йолалар. Ике томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 388 б.

*Давлетшина Л.Х.* О перевоплощениях духов-хозяев домашнего пространства (на материале татар Заказанья начала XXI века) // Вестник Башкирского университета. 2015. Т. 20. № 3. С. 1022–1025.

*Давлетшина Л.Х.* «Хызыр Ильяс» в традиционной культуре татар // Вестник Башкирского университета. 2011. Т. 16. № 3. С. 779–781.

*Дәүләтшин Г.М.* Төрки-татар рухи мәдәнияте. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 512 б.

Ислам. Белешмә-сүзлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 192 б.

*Кляшторный С.Г.* Древнетюркская мифология: к постановке проблемы // Письменные памятники и проблемы истории культуры народов Востока. Ч. 2. М.: Наука, 1979. С. 91–96.

*Кляшторный С.Г.* Древнетюркская цивилизация: диахронические связи и синхронические аспекты // СТ. 1987. № 3. С. 67–72.

*Кляшторный С.Г.* Древнетюркские рунические памятники как источник по Средней Азии. М.: Наука, 1964. 214 с.

*Кляшторный С.Г.* Мифологические сюжеты в древнетюркских памятниках // ТС. 1977. М.: Наука, 1981. С. 117–138.

Культ святых в сибирском исламе: специфика универсального / А.Г. Селезнев [и др.]. М.: Изд. дом Марджани, 2009. 216 с.

*Кюнер Н.* В. Китайские известия о народах Южной Сибири, Центральной Азии и Дальнего Востока. М.: Изд-во Восточной литературы, 1961. 392 с.

Материалы по истории сюнну (по китайским источникам). Вып. II / Предисловие, перевод и примечания В.С. Таскина. М.: Наука, 1973. 168 с.

Мифологический словарь / гл. ред. Е.М. Мелетинский. М.: Советская энциклопедия, 1990. 709 с.

Мифы народов мира: Энциклопедия: в 2 т. / под ред. С.А. Токарева. М.: Большая Российская энциклопедия, 2003. Т. 1. 671 с.

*Мовсес Каланкатуаци.* История агван Мойсея Каганкатваци, пис. X в. / пер. К. Патканьян. СПб.: Императорская Академия наук, 1861. 376 с.

*Неклюдов С.Ю.* Стереотипы действительности и повествовательные клише // Речевые и ментальные стереотипы в синхронии и диахронии. М., 1995. С. 77–80.

*Померанцева Э.В.* Мифологические персонажи в русском фольклоре. М.: Наука, 1975. 194 с.

*Потапов Л.П.* Алтайский шаманизм. Л.: Наука, 1991. 203 с.

*Потапов Л.П.* Умай – божество древних тюрков в свете этнографических данных // ТС. 1972. М.: Наука, 1973. С. 265–286.

*Садекова А.Х.* Идеология ислама и татарское народное творчество. Казань: Фикер, 2001. 206 с.

*Стеблева И.В.* К реконструкции древнетюркской религиозно-мифологической системы // ТС. 1971. М.: Наука, 1972. С. 213–226.

Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда. 2 т. Казан: Мәгариф, 2009. 360 б.

Татар халык мәкальләре: 3 томда / төз. Н. Исәнбәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 1 т. 623 б.

*Урманчеев Ф.И.* Татар халык иҗаты. Казан: Мәгариф, 2002. 172 б.

*Яхин Ф.* Сөләйман Бакыргани // Татар әдәбияты тарихы. I т. Казан, 2014.

***Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*
*leyla.davletshina@yandex.ru*